Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче Рус Кармәте авылында

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 30 ноябре № 7

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Рус Кармәте авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2020 елда Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге Рус Кармәте авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Рус Кармәт авылы эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту.

2) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

- Рус Кармәтендә су белән тәэмин итү системасы өчен материаллар, җиһазлар сатып алу һәм ремонтлау;

3) оештыру ритуаль хезмәтләр һәм күмү урыннарын карап тоту:

- Рус Кармәт авылы зиратында агачларны кисү.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы И. Р. Шакиров

СОВЕТ НОВОКИРЕМЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ